СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**01 ноября 2024 ел** **№ 7**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Мәмсә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Ташкичү авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Мәмсә авылында Мәмсә авылы, Г.Тукай урамы, 29 нчы йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 20 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Мәмсә авылында Мәмсә авылы, Г.Тукай урамы, 29 нчы йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану

мәсьәләсе буенча 2023 елның 20 ноябренә 17 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:

1 нче этап: Вахитов, Г.Тукай урамнарында яшәүчеләр;

2 нче этап: Алмалы, Киров урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәгемәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау (Киров урамы);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу, ут челтәрләрен төзекләндерү);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (зиратны тоту өчен җиһазлар сатып алу: бензин белән эшләүче чапкыч – 1 данә, коймаларны буяу өчен буяу сатып алу);

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне тәртипкә китерү (Тукай урамынын коесын төзекләндерү);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу,

аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (челтәрләренең аварияле участокларын өлешчә ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Алмалы урамнарында агачларны кисү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

5. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Мәмсә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына ТР, Арча районы, Мәмсә авылы, Г.Тукай урамы, 29 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ